**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**СТАРОЧЕЛНИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423004, с. Старые Челны, ул. Ленина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСКЕ ЧАЛЛЫ**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**

423004, Иске Чаллы авылы, Ленина ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Чаллы **ав.** **КАРАР**

**«29» март 2024 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 9 апрелендә 08 сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылы Чапаев, Синдряков, Совет, Гагарин урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 9 апрелендә 09 сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылы Ленин һәм Мәктәп, Мира, Молодёжная, Больничная урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Иске Чаллы торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенында чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 09.10.2023 ел, № 1 карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнар Җыенының 09.10.2023 ел, № 2 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

« РИЗА» «КАРШЫ» ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров